**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 21 октябрендәге 4447 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2013 елның 2 сентябрендәге 7774 номерлы**
**«Казан шәһәренең автомобиль юлларында**
**транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы**
**карарына үзгәреш кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Казан шәһәре автомобиль юлларындагы күпер корылмаларын саклау максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 2 сентябрендәге 7774 номерлы «Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9074 номерлы, 2014 елның 11 февралендәге 641 номерлы, 2014 елның 24 мартындагы 1580 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3973 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы 783 номерлы, 2021 елның 30 июлендәге 1917 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«1.2. 06.00 сәгатьтән алып 21.00 сәгатькә кадәр түбәндә күрсәтелгән урамнар буенча, рөхсәт ителгән массасы 5 тоннадан артык булган транспорт чаралары хәрәкәтен тыеп, Казан шәһәренең Киров дамбасы, Несмелов урамы, Зур Крыловка урамы, Мулланур Вахитов урамы, Чистай урамы, Фатыйх Әмирхан урамы, Чистай урамыннан алып «Миллениум» күперенә кадәр, «Миллениум» күпере, Вишневский урамы, Нурсолтан Назарбаев урамы, Габдулла Тукай урамы, Борһан Шәһиди урамы, Сәетгалиев урамы белән

чикләнгән автомобиль юлларында рөхсәт ителгән массасы 5 тоннадан артык булган транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү кертергә»;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенә (М.А.Савин) транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү гамәлдә булу чорында юл хәрәкәте иминлеген үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 2 сентябрендәге 7774 номерлы «Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**